**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«31» октябрь 2024 ел № 15

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 октябрендә, 30 октябрендә, 31 октябрендә узган: «2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
2) урам утларын карап тоту.
3) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, чыгаруны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
4) торак пункт территориясен төзекләндерү.
5) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 212 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 151 кеше катнашты.

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 134 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 17 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге Гайтән торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче

һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
2) урам утларын карап тоту.
3) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, чыгаруны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
4) торак пункт территориясен төзекләндерү.

традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Авдеева